КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**Республиканское агентство по печати и массовым коммуникациям**
Декабристов ул., 2, г. Казань, 420066
Тел.: (843) 570-31-22, факс: (843) 537-91-04
www.tatmedia.ru, www.tatmedia.tatarstan.ru
e-mail: ra.tatmedia@ tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
**Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы**
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066
Тел.: (843) 570-31-22, факс: (843) 537-91-04
www.tatmedia.ru, www.tatmedia.tatarstan.ru
e-mail: ra.tatmedia@ tatar.ru

ПРИКАЗ — БОЕРЫК

«21» апрель 2021 г. № 52-н

«Россия халыкларының милли бәйрәмнәре»
Бөтенроссия фотоконкурсы
үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары белән расланган «2014-2023 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында боерам:

1. «Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» Бөтенроссия фотоконкурсын уздыру турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга.
2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Ф.Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче — А.С.Сәлимгәрәев

«Татмедиа» республика
матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр
агентлыгының
2021 елның «21» апрель
52-п номерлы боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

**«Россия халыкларының милли бәйрәмнәре»**
**гомумроссия фотоконкурсын үткәрү турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» гомумроссия фотоконкурсы (алга таба – Конкурс) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары белән расланган «2014 – 2023 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасы нигезендә үткәрелә.

1.2. Конкурсның оештыручысы – «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – оештыручы);

1.3. Конкурс ел саен, календарь ел дәвамында, агымдагы елның 31 декабренә кадәр үткәрелә.

Конкурсны үткәрү турындагы мәгълүмат Конкурсны оештыручының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://tatmedia.tatarstan.ru) «Яңалыклар», «Конкурслар» бүлекләрендә урнаштырыла. Конкурс үткәрү турындагы мәгълүматта номинацияләр, Конкурска гаризалар кабул ителә башлау һәм төгәлләнү сроклары күрсәтелә.

## 2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурс түбәндәге максатларда оештырыла:

Россия Федерациясе күпмилләтле халкының милли-мәдәни бәйрәм традицияләрен саклап калуга һәм үстерүгә, киләчәк буыннарга тапшыруга өлеш керткән аеруча мөһим һәм талантлы фотоэшләрне ачыклау;

милләтара аралашу, рухи бердәмлек һәм үзара татулык культурасын булдыру;

җәмәгатьчелек игътибарын Россия Федерациясе халыкларының уңай милли-мәдәни үзенчәлекләре, иң яхшы традицияләрен саклап калу, үстерү проблемаларына җәлеп итү.

2.2. Конкурсның төп бурычлары:

тарихи мирасны, туган якның традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен сәнгати-эстетик кабул итүне тәрбияләү;

Россия халыклары тарихи һәм мәдәни мирасын, гореф-гадәтләренең күптөрлелеген популярлаштыру.

## 3. Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр

3.1. Гариза бирүче – әлеге Нигезләмәнең 5 бүлеге нигезендә гариза тапшырган һәм Конкурска тәкъдим ителә торган фотографияләрнең авторы һәм (яисә) аларга хокукы булган зат.

3.2. Катнашучы – Конкурста катнашырга рөхсәт ителгән фотографияләр авторы һәм (яисә) аларга хокукы булган зат.

3.3. Конкурс комиссиясе – фотоэшләрне бәяли торган затлар төркеме.

3.4. Конкурста җиңүче – призлы урын алган катнашучы.

## 4. Конкурста катнашучылар

4.1 Конкурста конкурс өчен тәкъдим ителгән эшләрнең авторлары һәм (яисә) бу эшләргә хокукы булган 18 яшькә җиткән затлар катнаша;

4.2. Конкурста Оештыручының рәсми сайтында күрсәтелгән срокларда гариза һәм эшләр тапшырган авторлар яисә авторлык коллективлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары сыйфатында теркәлгән редакцияләр катнаша (алга таба – ММЧ);

4.3. Фотоконкурста катнашу авторның (авторлык коллективының) яисә редакциянең эшләрне киләчәктә түләүсез нигездә, ләкин авторын (авторлык коллективын) яисә редакциясен һәм хезмәттәшлек итү чыганагын күрсәтеп, файдалануга (мәгълүмати, фәнни, белем бирү яисә мәдәни максатларда, шул исәптән фоторәсемнәрне халыкка күрсәтү һәм бастырып чыгару) рөхсәт бирүен аңлата;

4.4. Өченче затлар авторлык хокукларын үтәмәгән өчен җаваплылык эшләрне тәкъдим иткән катнашучыларга йөкләнә;

4.5. Гариза бирүчеләр Конкурста катнашу өчен әлеге Нигезләмәнең 5 бүлегендә бәян ителгән тәртиптә һәм анда күрсәтелгән шартларны, таләпләрне үтәп документлар әзерләргә һәм тапшырырга тиеш;

4.6. Гариза бирүче Конкурсның бер номинациясендә катнашу өчен бер генә гариза бирә ала;

4.7. Конкурска гариза бирүче берничә номинация буенча документлар тапшыра ала, бу очракта жюри тарафыннан карала торган документлар һәрбер номинация буенча аерым әзерләнергә тиеш.

## 5. Конкурсны үткәрү шартлары

5.1. Конкурста катнашу өчен түбәндәге документлар кабул ителә:

а) конкурс эшләре (фотографияләр) флешкартада яисә яисә «облако» виртуаль саклагычына актив сылтама белән тапшырыла;

б) әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә анкета-заявка, конкурс эшләренә аннотация белән;

в) юридик зат буларак теркәлгән массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен түбәндәге документлар тапшырыла:

юридик затны салым органында исәпкә кую турында таныклык (ИНН) (күчермәсе);

юридик зат җитәкчесен вазыйфага билгеләп кую турында боерык (күчермәсе);

гамәлгә кую документлары (күчермәләре);

ММЧ теркәү турында таныклык (күчермәсе) – массакүләм мәгълүмат чаралары өчен;

г) юридик зат булмаган массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык (күчермәсе) йә теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан өземтә;

массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе уставы яисә, массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясендә кимендә 10 кеше эшләсә, «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-I номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – ММЧ турында Закон) 20 статьясы нигезендә аны алмаштыра торган шартнамә;

з) физик затлар (авторлар, авторлык коллективлары) өчен:

шәхесне таныклый торган документ (күчермәсе);

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә Персональ белешмәләрне эшкәртүгә, тапшыруга ризалык бирү;

персональ белешмәләрне эшкәртүгә, тапшыруга ризалык (әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада бирелгән рәвештә);

персональ белешмәләр субъекты рөхсәт иткән персональ белешмәләрне таратуга ризалык (3 нче кушымта);

е) авторлар коллективлары һәм ММЧ редакцияләре өчен:

конкурс эшенә призлы урын бирелгән очракта акчаны процентлап бүлешү турында килешү.

Әлеге пунктның «б» – «е» пунктчаларында күрсәтелгән документлар кәгазь вариантта (оешма җитәкчесенең имзасы белән тамгалана һәм оешма мөһере (булган очракта) сугыла) яисә сканердан чыгарып, PDF форматында электрон документ рәвешендә җибәрелә.

5.2. Конкурска килгән эшләргә рецензия бирелми

Катнашу өчен бирелгән гариза эшләрне конкурсантлар исемлегенә кертү өчен нигез булып тора. Конкурста катнашу өчен анкета-заявка tatmedia.tatarstan.ru порталында “Конкурслар һәм проектлар” бүлегендә урнаштырылган;

5.3. «Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» конкурсында катнашу өчен анкета-заявка, фотоэшләр Конкурсның оештыру комитетына электрон почта аша foto-konkurs2021@mail.ru адресына яисә «Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» конкурсына билгесе белән «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгына (420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт, 608 каб.) җибәрелә. Тел/факс: 8 (843) 570-31-12.

5.4. Конкурсны оештыручының рәсми сайтында күрсәтелгән датага алынмаган эшләр, кабул ителми.

5.5. Анкета-гаризаны һәм яисә конкурс эшен билгеләнгән срокны бозып тапшыру, анкета-гаризаның һәм (яисә) конкурс эшенең булмавы, анкета-гаризаның конкурс эшенең әлеге Нигезләмәгә туры килмәве, сурәтендә хилафлыклар булган эшләрне тәкъдим итү Конкурста катнашуга рөхсәт бирмәү өчен нигез булып тора;

5.6. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (почта, командировка һ.б.) Гариза бирүче тарафыннан мөстәкыйль түләнә.

5.7. Конкурска коллажлар, язулар, дата, кысалар һәм почмаклар өстәлгән, шулай ук фотомонтаж ярдәмендә үзгәртелгән, фотостудиядә төшерелгән, Россия Федерациясе дәүләт органнары оештырган конкурсларда катнашкан һәм призлы урыннар алган фотоэшләр кабул ителми.

5.8. Фотографияләр jpeg форматында, кадрның максималь саклангaн иң зур ягының размеры кимендә 4000 пиксель булырга тиеш;

5.9. Тапшырылган фотографияләр Агентлыкның рәсми сайтында конкурс турында игълан ителүгә бер ел кала төшерелгән булырга тиеш.

5.10. Катнашучыга Конкурска кертелмәү турында хәбәр әлеге Нигезләмәнең 5.1. пунктында каралган документларны алган мизгелдән алып биш эш көне дәвамында Оештыручы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) имзалаган һәм анкета-гаризада күрсәтелгән адреска җибәрелгән заказлы рәсми хат белән хәбәр ителә.

## 6. Конкурсның номинацияләре

6.1. Конкурс түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә:

«Иң яхшы фото» (әлеге номинациягә бер генә фотография тапшырылырга мөмкин);

«Фотоэшләр сериясе». Әлеге номинация конкурс максатларына туры килә торган фотоэшләрдән җыелманы күздә тота (кимендә 3 һәм иң күбе 6 фоторәсем);

«Портрет» (әлеге номинациягә бер генә фотография тапшырылырга мөмкин).

## 7. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

7.1. Конкурс эшләрен бәяләгәндә түбәндәге критерийлар исәпкә алына:

Конкурс тематикасын чагылдыра торган эчтәлек (0-5 балл);

эшнең кабатланмаган һәм оригиналь булуы (0-5 балл);

үтәлеш сыйфаты (0-5 балл);

эшкә иҗади якын килү (0-5 балл).

7.2. Конкурс комиссиясе эшкә гомуми баллны конкурс эшләренә комиссиянең барлык әгъзалары куйган бәядән чыгып билгели.

7.3. Эшләр циклын бәяләү циклда тәкъдим ителгән барлык эшләрне бергә карауны һәм бәяләүне күздә тота.

## 8. Оештыру комитетын һәм конкурс комиссиясен оештыру һәм аның эшчәнлек тәртибе

8.1 Оештыру комитетының һәм конкурс комиссиясенең составы Конкурсны оештыручы боерыгы белән 8 кешедән раслана һәм рәистән, комиссия әгъзаларыннан гыйбарәт була;

8.2. Оештыру комитеты мәдәният һәм сәнгать өлкәсе белгечләреннән, Татарстан Республикасы Фотографлар берлеге вәкилләреннән төзелә;

8.3. Конкурс комиссиясенең эше утырышларда гамәлгә ашырыла. Утырышта комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, утырыш тулы хокуклы дип таныла.

8.4. Конкурс комиссиясе эшенә рәис җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда, рәис вазыйфалары аның тарафыннан билгеләнгән урынбасарына йөкләнә.

8.5. Конкурс комиссиясе балларның гомуми суммасы буенча һәрбер номинациядә Конкурста катнашучыларның рейтингын төзи. Рейтинг нигезендә һәрбер номинация буенча Конкурста җиңүчеләр билгеләнә;

8.6. Конкурс комиссиясе әгъзалары конкурска тапшырылган эшләрне әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары буенча бәяли. Һәрбер критерий буенча балларның саны 5 баллы шкала (0 – 5 балл) буенча бәйләнә. Конкурс эше дөрес номинациягә тапшырылмаган булса, ул “0” балл белән бәяләнә;

8.7. Конкурс эше әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәсә, конкурс комиссиясе карары белән әлеге эш Конкурста катнашудан төшереп калдырыла;

8.8. Бер номинациягә бер генә гариза тапшырылса, бер гариза да тапшырылмаса, тапшырылган гаризаларның берсе дә конкурс шартларына туры килмәсә, катнашкан эшләрнең берсе дә билгеләп үтәргә лаек дип танылмаса, Конкурс бу номинациядә үткәрелмәгән дип танылa һәм моның өчен тәгаенләнгән акчалар Оештыручы тарафыннан башка номинацияләр арасында тигез итеп бүленә.

8.9. Җиңгән эш иҗат коллективы тарафыннан тәкъдим ителгән булса, номинациянең әлеге урыны өчен тәгаенләнгән акчалар җиңүчеләр арасында документлар белән бергә тапшырыла торган килешү нигезендә тигез өлешләп бүленә.

8.10. Тавышлар саны тигез булганда конкурс комиссиясе әгъзалары тавыш бирә һәм бу номинациядә Конкурсның җиңүчесе билгеләнә.

8.11. Конкурсны оештыручы оештыру-техник эшчәнлекне җайга салу, утырышны әзерләү һәм конкурс комиссиясе документациясен алып бару өчен җаваплы секретарь билгеләп куя.

8.12. Җаваплы секретарь түбәндәгеләрне башкара:

материалларны конкурс комиссиясе тарафыннан карауга әзерли һәм аларның сакланышын тәэмин итә;

конкурс комиссиясе әгъзалары белән элемтәдә тора;

конкурс комиссиясе утырышларын әзерли;

конкурс комиссиясе беркетмәләрен рәсмиләштерә;

8.13. Җаваплы секретарь конкурс комиссиясе составына керми һәм утырышларда тавыш бирү хокукыннан башка гына катнаша.

8.14. Конкурс комиссиясе утырышы уздырылган көннән алып биш эш көне эчендә Конкурс комиссиясе утырышы йомгаклары буенча беркетмә рәсмиләштерелә, аңа утырышта булган конкурс комиссиясе әгъзаларының имзасы салына, беркетмә конкурс комиссиясе рәисе яисә рәисе урынбасары тарафыннан раслана.

## 9. Финанс белән тәэмин итү

9.1. Конкурсны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле финанс чыгымнары Оештыручыга Конкурсны үткәрү өчен Татарстан Республикасы бюджетында «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә

ашыру» дәүләт программасы кысаларында тиешле ел өчен каралган акчалар исәбеннән финанслана.

9.2. Гомуми приз фонды 225 000 сум тәшкил итә;

9.3. Әлеге Нигезләмәнең 6.1 пунктында күрсәтелгән номинацияләр буенча Конкурста җиңүчеләр I, II һәм III дәрәҗә дипломнар белән бүләкләнә. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү датасы Конкурсны оештыручының рәсми сайтында өстәмә хәбәр ителә.

9.4. Конкурста җиңүчеләр түбәндәге түбәндәге номинацияләрдә премияләр һәм дипломнар белән бүләкләнә:

**«Иң яхшы фото»**

I дәрәҗә диплом һәм 30 000 сум;

II дәрәҗә диплом һәм 22,5 000 сум;

III дәрәҗә диплом һәм 15 000 сум.

**«Фотоэшләр сериясе»**

I дәрәҗә диплом һәм 40 000 сум приз;

II дәрәҗә диплом һәм 30 000 сум приз;

III дәрәҗә диплом һәм 20 000 сум приз.

**«Портрет»**

I дәрәҗә диплом һәм 30 000 сум приз;

II дәрәҗә диплом һәм 22,5 000 сум приз;

III дәрәҗә диплом һәм 15 000 сум приз.

9.5. Җиңүчеләргә акча конкурска йомгак ясалган һәм беркетмәгә имза салган мизгелдән алып 20 көн дәвамында аларның Оештыручыга язган хатында күрсәтелгән реквизитлар буенча исәп-хисап счетына күчерү юлы белән түләнә.

9.6. Җиңүчеләрне бүләкләү датасы һәм урыны турында Конкурсны оештыручының рәсми сайтында «Яңалыклар» бүлегендә (https://tatmedia.tatarstan.ru) өстәмә хәбәр ителә.

## 10. Аерым шартлар

10.1. Оештыручылар түбәндәгеләргә хокуклы:

- әлеге Нигезләмәдә һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән очраклардан, шулай ук бәхәсле очраклардан тыш, Конкурста катнашучылар белән язмача йә башка төрле элемтәләргә кермәскә;
- эшләрне тапшыру срогының беренче яртысында Россия Федерациясе законнары таләпләрен (РФ ГК 1058 ст.) үтәп, Конкурсны туктатырга яки әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, бу хакта Агентлыкның рәсми сайтында (https://tatmedia.tatarstan.ru) «Яңалыклар» бүлегендә һәм Министрлыкның рәсми сайтында (https://mvd.tatarstan.ru) «Яңалыклар» бүлегендә тиешле мәгълүмат урнаштырып, Катнашучыларга хәбәр итәргә.

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2021 елның «21» апрель 52-п номерлы боерыгы белән расланган «Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» гомумроссия фотоконкурсын үткәрү турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

**«Россия халыкларының милли бәйрәмнәре»**
**гомумроссия фотоконкурсында катнашу өчен**

## АНКЕТА-ГАРИЗА

**Автор (яисә иҗат коллективы):**

**Номинация исеме:**

**Эшнең исеме:**
______________________________________________________________________________________________

**Кыскача аннотация:**
______________________________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________________________

**Телефон/факс:**
____________________________________________________________________________________

**Электрон адрес:**
________________________________________________________________________________________

**Адрес**______________________________________________________________________

______________________________________________________________

**Эшләргә хокукы булган затның ризалыгы**

- Эшләрне яки аларның фрагментларын киләчәктә мәгълүмати, фәнни, уку-укыту яисә мәдәни максатларда түләүсез, ләкин авторның исемен һәм алынган чыганакны күрсәтеп файдалануга, шул исәптән гавами күрсәтүгә һәм бастырып чыгаруга РИЗАЛЫК БИРӘМ;
- персональ белешмәләрне эшкәртүгә һәм тапшыруга РИЗАЛЫК БИРӘМ.

______________________________________________________________

________________________

(ФИ Ат. ис*, имза)

Эшләр һәм әлеге гаризаның төп нөсхәсе «Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» гомумроссия фотоконкурсының оештыру комитеты тарафыннан түбәндәге адрес буенча алынырга тиеш:
420066, Казан, Декабристлар урасы, 2
«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы
Тел/факс: (843)570-31-12
E-mail: foto-konkurs2021@mail.ru
“Россия халыкларының милли бәйрәмнәре” гомумроссия фотоконкурсының оештыру комитеты

*Атасының исеме булган очракта күрсәтелә

«Татмедиа» республика
матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгының
2021 елның «21» апрель
52-п номерлы боерыгы белән
расланган
«Россия халыкларының милли
бәйрәмнәре» гомумроссия
фотоконкурсын үткәрү турында
нигезләмәгә
2 нче кушымта

**Персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин,_______________________________________________________________,
яшәү адресым_____________________________________________
_____________________________________________________________________,
шәхесне таныклаучы төп документым (паспорт)____________________
_____________________________________________________________________
_________________________________, «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә "Татмедиа" республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба – оператор) (адресы: 420097, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) «Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» гомумроссия фотоконкурсында катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне эшкәртүгә, аларны җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), алардан файдалануны, аларны таратуны (шул исәптән башкаларга тапшыруны), үз исемемнән башка файдалануны, блокировать итүне, юкка чыгаруны да кертеп, ризалыгымны бирәм.
Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге:

| | |
|---|---|
| Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге: | (фамилия, исем, атасы исеме, җенес, туган көн һәм урын, гражданлык, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (документ төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан бирелүе), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән кәрәзле телефон), электрон почта адресы, Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счеты турында белешмәләр) |

Әлеге ризалык имзаланган көннән алып 1 (бер) ел гамәлдә була.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны, бу хакта операторга язмача хәбәр итеп, кире алырга хокуклы.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алган очракта оператор аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм, персональ белешмәләрне эшкәртү өчен аларны саклау башкача кирәк булмаса, ризалыкны кире алу турында мөрәҗәгать кергән көннән алып утыз көн эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) тиеш. Күрсәтелгән вакыт эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор аларны блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм персональ белешмәләрне иң күп дигәндә алты ай эчендә юкка чыгара.

_________________________________________________/________________

(персональ белешмәләр субъектының Ф.И.Ат ис. (булган очракта күрсәтелә) һәм имзасы)

________________

(Дата)

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2021 елның «21» апрель 52-п номерлы боерыгы белән расланган «Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» гомумроссия фотоконкурсын үткәрү турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

**Тарату өчен персональ белешмәләр субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин, ____________________________________________,
(фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта) рус телендә)

____________________________________________,
(почта адресы)

____________________________________________,
(электрон почта адресы)

____________________________________________,
(телефон номеры)

«Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның $10^1$ статьясы нигезендә «Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» гомумроссия фотоконкурсын оештыручы «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (ОГРН 1031621014765, ОКТМО 92701000, ОКПО 14912163) юридик адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары өчен Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган республика журналистлар конкурсында катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне таратуга (шул исәптән башкаларга тапшыруга, бирүгә) ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Ризалык | |
|---|---|---|---|
| | | Әйе | ЮК |
| Гомуми персональ белешмәләр | | | |
| | Фамилия | | |
| | Исем | | |
| | Атасы исеме (булган очракта) | | |
| | Туган ел, ай, дата һәм урын | | |
| | Адрес | | |
| | Белем | | |
| | Һөнәр | | |

Эшкәртү өчен шартлар һәм тыю билгеләнә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге |
|---|---|---|
| **1. [Персональ белешмәләрнең категориясе]** | | |
| | **[Персональ белешмәләрнең исемлеге]** | |

Искәрмә. Күрсәтелгән таблица персональ белешмәләр субъектының теләге буенча, персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан чикләүләрсез тутырыла.
Шартлар һәм тыюлар операторның чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына әлеге персональ белешмәләрне таратуга һәм (яисә) тапшыруга бәйле гамәлләрен чикләүне йә тыюны күздә тота.
Ризалыкта өстәмә шартлар да күрсәтелергә мөмкин, алар алынган персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан мәгълүмат кайбер хезмәткәрләргә генә җиткерелә торган эчке элемтәләр буенча йә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша тапшыруны, яки алынган персональ белешмәләрне тапшырмауны күздә тота

Операторның персональ белешмәләр субъектының персональ белешмәләре чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына тапшырылырга мөмкин мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр: http://tatmedia.tatarstan.ru/.

Әлеге ризалык ______________________________ срокта гамәлдә була.

(ризалыкның гамәлдә булу срогы)

Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тартырга хокуклы.

Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тарткан очракта оператор мондый баш тартуны алган көннән алып иң күбе утыз көн эчендә аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм, элек куелган максатлар өчен персональ белешмәләрне эшкәртү башкача таләп ителмәсә, персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) тиеш.

Күрсәтелгән срокта персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор мондый персональ белешмәләрне блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм персональ белешмәләрне алты айдан артмаган срокта юкка чыгаруны тәэмин итә.

______________( персональ белешмәләр субъекты имзасы)
______________ (число, ай, ел)